РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14 » 04 2026 ел №420

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 18.02.2025 № 162 карары белән расланган Ютазы муниципаль районында гражданнар оборонасы буенча чараларны тәэмин итү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Гражданнар оборонасы турында" 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау хакында»гы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 26 ноябрендәге 804 санлы карары, "Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында"гы 2020 елның 20 февралендәге 10-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 18.02.2025 № 162 карары белән расланган Ютазы муниципаль районында гражданнар оборонасы буенча чараларны тәэмин итү турындагы нигезләмәгә (алга таба - нигезләмә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5. Гражданнар оборонасы буенча мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган куркынычлар турында халыкка хәбәр итүгә бәйле бурычларны хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган төп чаралар булып түбәндәгеләр тора:
халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән муниципаль һәм локаль халыкка хәбәр итү системаларын булдыру, реконструкцияләү һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту;

кешеләр күпләп була торган урыннарда халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирүнең махсуслаштырылган техник чараларын урнаштыру;

Россия Федерациясенең бердәм электр элемтәсе челтәре чараларыннан, радио, чыбыклы һәм телевизион тапшырулар челтәрләреннән һәм чараларыннан, мәгълүмат тапшыруның башка техник чараларыннан комплексны файдалану. Күрсәтелгән чараны үтәүне оештыру «Таттелеком» ГАЖ Әлмәт ЗУЭС БРУЭС Ютазы цехына йөкләнә;

мәгълүмат җыю һәм аны алмашу.».

1.2. Нигезләмәнең 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Гражданнар оборонасы буенча мобилизация чорында, сугыш хәле гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар нәтиҗәсендә килеп чыккан янгыннарга каршы көрәшкә бәйле бурычларны хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган төп чаралар булып түбәндәгеләр тора:

янгынга каршы кирәкле көчләр булдыру, аларны җиһазландыру һәм гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкарылган районнарда янгыннарны сүндерү;

билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категорияләренә кертелгән объектларда янгыннарны сүндерү. Күрсәтелгән чараларны үтәүне оештыру Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе ГПС ФПСның 42 ПСЧ 11 ПСОга йөкләнә (килешү нигезендә).»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Р.М. Якупов
(8-85593) 2-42-05